| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 май г.Казань № 405

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы; 2015 ел, 26 август, 623 нче; 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы; 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче; 2017 ел, 10 май, 269 нчы; 2018 ел, 30 июль, 613 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1179 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1302 нче; 2019 ел, 13 июль, 577 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1057 нче; 2020 ел, 6 март, 178 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.19 нчы пунктның җиденче абзацында «медицина ярдәме стандартлары» сүзләрен «медицина хезмәткәрләре күрсәтә торган медицина ярдәменең медицина ярдәме сыйфатын бәяләү критерийларына туры килүе» сүзләренә алыштырырга;

4.2 нче пунктның икенче абзацында «медицина ярдәме стандартлары» сүзләрен «медицина хезмәткәрләре күрсәтә торган медицина ярдәменең медицина

ярдәме сыйфатын бәяләү критерийларына туры килүе» сүзләренә алыштырырга;

3.3.39 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.39. Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары исемлеген раслау.».

2. Бу карарның 1 пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин